БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
15 декабрь 2022ел

**КАРАР**
№ 162

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Салавыч авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планын раслау турында**

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Салавыч авыл җирлеге территориясен шәһәр төзелеше планлаштыруын гамәлгә ашыру максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 24 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14,15 статьяларына, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставына таянып, гавами тыңлаулар һәм килештерү комиссиясе нәтиҗәләре буенча, Татарстан Республикасы Балтач район Советы **карар бирде:**

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Салавыч авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планын расларга.

2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Салавыч авыл җирлеге башкарма комитетына:

- әлеге карарның 1 пункты белән расланган генераль план нигезендә шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашырырга;
- Салавыч авыл җирлеге торак пунктлары чикләрен Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрына кертергә;
- Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Салавыч авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планын раслау турында карарны Территориаль планлаштыруның федераль дәүләт мәгълүмат системасына урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетына Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Салавыч авыл җирлеге башкарма комитеты белән берлектә Салавыч авыл җирлегенең Биктәш торак пункты территориясен киңәйтүнең мөмкин булган вариантларын өйрәнергә.

4. Әлеге карарны baltasi.tatarstan.ru Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Балтач муниципаль районы башлыгы,
Балтач район Советы рәисе — Р.Р. Нотфуллин